Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 18 18.01.2016 ел

**Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, 2004 елның 24 мартындагы 18 статьясына ярашлы № 23-ЗРТ «җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Илдерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы карары:

1. Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2016 елның 6 мартында якшәмбе көнне 7.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2016 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә урнашкан, шулай ук теркәлмәгән, әмма җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә яшәүче яки милекләре булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын бер тапкыр түләүне кертүгә , 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

**Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту.**- Торак пунктларда зиратларның коймаларын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу:

- Иске Илдерәк авылы-30 мең сум;

Чуваш Енорускино авылы 30 мең сум;

**Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.**

- вак таш белән капланган юлларны ремонтлау, шул исәптән:

Иске Илдерәк авылында-Совет урамы-30 мең сум;
Гагарин урамы -30 мең сум;
Яшьләр урамы -36 мең сум;
Яңа Илдерәк авылында – Үзәк урам -30 мең сум;
Чуваш Енорускино авылында Көнчыгыш урамы -30 мең сум;
Бакча урамы -12 мең сум;
Тарханка авылында Көнчыгыш урамы -33 мең сум;

Илеш авылында-Төньяк урамы-24 мең сум;

**Торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле керүен тәэмин итү;**

- Чуваш Енорускино авылындагы чишмәне ремонтлау-15 мең сум.

**«РИЗА КАРШЫ».**

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясе чикләрендә референдум округын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге башкарма комитетына 18 яшькә җиткән сайлаучылар исемлеген төзергә һәм Иске Илдерәк авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә раслау өчен тапшырырга.

5. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге участок сайлау комиссиясе гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

6. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Аксубай муниципаль районы
Иске Илдерәк авыл җирлеге
Совет Рәисе: В.К. Альметкин